**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**10.12.2024** **№ 147**

**Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәткә түләүне оештыру һәм шартлары турында 28.05.2019 ел № 159 Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 маендагы 159 нче номерлы карары белән расланган “Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең” (22.09.2020 ел № 9, 06.12.2022 ел № 82, 24.06.2024 ел №133 Иске Маврин авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән), 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә, "Баш бухгалтер" һәм "Бухгалтер" юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Баш бухгалтер | 25 700 сум | 27 000 сум |
| Бухгалтер | - | 24 500 сум |

2. Штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы Иске Маврин  авыл җирлегенең рәсми сайтында.
4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Нургалеев**